№5, Март 2025

# Чишмә башы

МБГБУ “Урта Курса төп гомуми белем мәктәбе”



**Бу санда:**

- *8 нче Март – Халыкара хатын-кызлар көне*
- *Ай вакыйгалары*
- *Каникуллар файдага үтсен*
- *Ял сәгатьләрендә*

**Яз килә**

*Көннәр аяз, күктә алсу*
*Нур сибеп, кояш көлә.*
*Җиргә тама көмеш тамчы –*
*Сагынып көткән яз килә.*
*Әйтегезче, кайсы вакыт*
*Яздагыдан ямьлерәк?*
*Кыш айларын да яратам,*
*Әмма яз күңеллерәк.*
*Көннәр җылы, күктә алсу*
*Нур сибеп, кояш көлә.*
*Җәйге шатлык, көзге бәхет*
*Яз белән бергә килә.*

*Мөнир Мазунов*



# 8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне



Яз кояшы елмаеп карап, табигатьнең уяна башлаган мәлендә язның тәүге бәйрәме - Халыкара хатын-кызлар көнен бәйрәм итәбез. XX гасыр башында 8 нче март – дөньяда иң танылган көннәрнең берсе булган. Бу көнне АКШ, Алмания, Нидерландлар, Франция, Австрия һәм башка бик күп илләрнең хатын-кызлары, үз хокукларын яклап, чыгышлар ясаганнар. Ул вакытларда әле 8 нче март бәйрәм түгел, көрәш көне булган. Безнең илебездә дә сәнәгать һәм оешмаларда эшләүче хатын-кызлар митингларга җыелганнар. 1965 нче елдан 8 нче март рәсми рәвештә халыкара бәйрәмгә әйләнә. Үзенең кыйммәтен бүгенгәчә югалтмаган сирәк бәйрәмнәребезнең берсе ул. Аннан соң бик күп бәйрәмнәр барлыкка килсә дә, килешәсездер, бу бәйрәм әле дә иң көтеп алынганы, иң матуры.

Хөрмәтле дәү әниләребез, әниләребез, кадерле кызлар, апа-сеңелләр! Сезне барыгызны да Халыкара хатын – кызлар бәйрәме – 8 нче Март белән тәбрик итәбез!



Язның әлеге бәйрәме җанга рәхәтлек, ял алып килә. Шушы бәйрәм көне Сезгә, елмаеп балкыган кояш матурлыгын, табигатьнең самимилеген өстәп, күңелләрегезгә шатлык, тәнегезгә саулык, өйләрегезгә иминлек алып килсен. Сезне матур бәйрәмегез белән чын күңелдән тәбрик итәбез! Ныклы сәламәтлек, бәхет, якыннарыгызның хөрмәтен һәм сөюен, иминлек, бөтен изге эшләрегездә яңадан-яңа уңышлар телибез! Хатын-кызлар - гаилә учагын сүндерми саклап тотучылар. Сезнең алда без баш иябез, сезнең белән горурланабыз!!!

## Ай вакыйгалары



Мәктәбебезнең “Җиңү волонтёрлары” хәрәкәте активистлары һәм Айрат Галәветдинов исемендәге “Юнармия” отряды члennnары тыл ветераннарын һәм МХОдә катнашучы якташларыбызның әниләрен 8 нче Март бәйрәме белән котладылар. Хөрмәтле ветераннарыбыз, балалары өчен ут йотып яшәүче әниләр! Сезгә җан тынычлыгы, куанычлы хәбәрләр, сабырлык телибез!

8 нче Март Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан мәктәбебездә укучылар һәм укытучылар көче белән бәйрәм оештырылды. Тыл ветераннары, МХОдә катнашучы якташларыбызның әниләре, укучыларыбызның әниләре, дәү әниләре бәйрәмнең кадерле кунаклары булдылар. Укучылар җырлары, биюләре белән кунакларга, әниләргә, дәү әниләргә якты мизгелләр, шатлык-сөенечләр бүләк иттеләр.





Сарай-Чокырча башлангыч мәктәбендә “Әни генә!” дип исемләнгән бәйрәм чарасы узды. Укучылар үзләренең әниләрен котлап җыр-биюләрен, шигырьләрен башкардылар, үз куллары белән ясаган бүләкләрен тапшырдылар. Әниләргә бәйрәм тамашасы бик ошады, алар балаларга, укытучылар коллективына олы рәхмәтләрен җиткерделәр.

10-15 нче март аралыгында мәктәбебездә тарих һәм җәмгыять белеме атналыгы узды. Ачык дәресләр, кызыклы биремнәр, конкурслар атна буе дәвам иттеләр һәм укучыларны кызыклы, иҗади белем дөньясына тарттылар. Укучыларыбызга әлеге фәннәр буенча белемнәрен күрсәтеп алырга, тулыландырырга һәм ныгытырга менә дигән мөмкинлек булды!



# Ай вакыйгалары






2025 елның 16 мартында гомумкырым референдумын уздыруга 11 ел тулды, аның барышында Кырым һәм Севастополь халкы Россия белән янадан кушылу өчен тавыш бирде. Референдум нәтиҗәләре нигезендә 2014 елның 18 мартында Кырым Республикасын һәм Севастопольне РФ составына кабул итү турында шартнамә имзаланды. 2014 елда Артек Кырым белән бергә Россиягә кайта. 11 ел эчендә лагерь модернизацияләнде һәм илнең алдынгы белем бирү үзәгенә әверелде. Ул һәр балага үз сәләтен максималь рәвештә аңларга мөмкинлек бирә. 17 нче мартта "Мөһим сөйләшүләр" дәресе дә "Кырым һәм Севастопольнең Россия белән янадан кушылу көне. Артекның 100 еллыгы" темасына багышланды.

“Сөйлә миңа - мин онытырмын, күрсәт - истә калдырырмын, кызыксындыр - өйрәнермен”. Әлеге сүзләр, әлбәттә, проект эшчәнлеге турында, чөнки нәкъ менә шушы эшчәнлек укучыларны эзләнүгә, иҗади фикерләүгә тарта. 17-20 нче март көннәрендә мәктәбебезнең 4-9 нчы сыйныф укучылары төрле фәннәрдән проект эшләре якладылар. Темалар да берсеннән берсе кызыклы һәм актуаль иде.







20 нче мартта 1 нче сыйныфта Әлифба бәйрәме узды. Җир йөзендә кем генә булмасын, кайда гына хезмәт итмәсен, ул зур дулкынлану белән үзенең нәни кулларына тәүге тапкыр әлифба алганын искә төшерә. Чөнки һәркемнең дә белем дөньясына аяк атлавы Әлифбадан, Азбукадан башланган. Димәк, Әлифба китабы озын гомерле, тирән мәгънәле, бәһасез байлык ул. Бәйрәмдә балаларның әти-әниләре дә катнашты. Әлифбаны тәмамлау - беренче сыйныф укучыларының мәктәп дигән белем йортындагы беренче җиңүләре. Хәрефләр белән танышу, алардан иҗекләр, сүзләр төзү җиңел булмады. Әмма алар тырышып белем алдылар: укырга, язарга өйрәнделәр. Әлифба аларны дус, тату булырга, укучылар өчен кагыйдәләрне үтәргә өйрәтте. Бәйрәм бик күңелле үтте, 1 нче сыйныф укучыларына киләчәктә дә уңышлар телибез!

Мәктәбебездә Нәүрүз бәйрәме гөрләп узды. Нәүрүз – татар халкының иң матур йола бәйрәмнәреннән берсе. Бу бәйрәм безнең төбәкләрдә, язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме булып санала. Ул – дуслык, киң күңеллелек, кунакчыллыкны үз эченә ала. Нәүрүз – фарсыча “яңа көн” дигәнне аңлата, икенче төрле язгы Яңа ел, дип тә әйтәләр. Бу көнне кешеләр кунак чакыралар, бер-берсенә булган үпкә-ачуларын оныталар, җырлыйлар һәм бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар, уеннар уйныйлар. Бәйрәм хуҗасы – Нәүрүзбикә. Бәйрәмне без дә бик күңелле билгеләп уздык: җыр-бию, табышмак-мәкаль әйтешү, матур теләкләр – барысы да булды!



# Каникулллар файдага үтсен дисәң...

Шактый озын тоелган 3 нче чирек тә үтеп китте... Әйе, сизелмичә дә үтте ул. Кызыклы дәресләре, күңелле тәнәфесләре, линейкалар, ярыш-конкурслар, бәйрәмнәр, чаралар, акцияләр, проект эшләре, тәрбия дәресләре, дисеңме... Хәер, сизелергә вакыты да булмаган икән шул аның. 21 нче март, 3 нче чирекнең соңгы көне, куркынычсызлык кагыйдәләрен кабатладык, үтибез дип куллар куйдык, күңелләрдә шатлык – куанычның иге-чиге юк, әлбәттә. Шулай да, каникул дип, онытылырга ярамас. Соңгы линейкада каен бөресе, макулатура, Бөтенрәсәй тикшерү эшләре дигән сүзләр колакка чалынды кебек. Иң мөһиме, зарыгып-сагынып көткән җәйге каникулларга кадәр әле 4 нче чирек бар, ә аның үз мәшәкатьләре, үз бурычлары. Димәк, язгы каникулда эш белән ялны алданрак планлаштырып куюың хәерле.



Каенның бөресе дә, яфрагы да, суы да, кайрысы да файдалы. Гадәттә, бөреләрне ачыла башлаганчы, гыйнвардан алып апрель башына кадәр җыялар.

Иң җайлы ысул – кышын ботакларны кисеп алып кайтып, җил йөри торган урында 2-3 атна киптерү.

Үз вакытында җыелган бөредә эфир майлары, С витаминьы, каротин, алколоидлар, май кислоталары бар, микроэлементлар күп. Файдалы үзенчәлекләреннән бактерияләргә каршы көрәшүдә нәтиҗәлелеген билгеләргә кирәк.

Экологлар әйтүенчә, макулатура җыю урман саклауның нәтиҗәле чараларыннан берсе булып тора. Акциянең максаты – кешеләрне калдыклар белән эш итүдә һәм яшь үсентеләр утыртуда җаваплылыкка өндәү. Мәктәпләрдә макулатура җыю үсеп килүче буынны экологияне һәм агачларның гомерен саклауга җәлеп итү өчен яхшы мөмкинлек кенә түгел, ә укучыларны актив иҗтимагый эшчәнлеккә җәлеп итү өчен дә мөһим. 100 кг макулатура бер агачның гомерен саклап кала ала.





*Яллар күңелле, файдалы һәм куркынычсыз үтсен өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк соң?*

- Юлда йөрү кагыйдәләрен үтә.
- Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен онытма.
- Җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтә.
- Өйдә үзең генә булу кагыйдәләрне үтә.
- Бозлавык булса егылудан саклан.
- Кичке сәгать сигездән соң урамга ялгызың гына чыкма.
- Биек биналарның астында, төзелеш барган урыннарда уйнама.
- Олылардан башка елга буйларына барма.
- Буш вакытыңны файдалы үткәр.
- Хуҗалык эшләрендә катнаш.
- Телефоннан сөйләшү, аралашу кагыйдәләрен үтә.

*Буш вакытны файдалы һәм кызыклы үткәрү өчен*

***Матур әдәбият уку.*** Элек-электән кеше күңелендә иң җылы, нечкә хисләр, матурлык — нәфислек, әдәплек, яктылык уятучы, дөньяны күрә белергә, кеше булырга өйрәтүче көчләрнең берсе – матур әдәбият уку.

***Кичке ашлар әзерләү.*** Бала өчен дә, өлкәннәр өчен дә файдалы булачак. Хобби, уку, дус-ишләр хакында серләшеп була.

***Әйберләрне бергәләп ремонтлау.*** Кран төзәтү, машинаның тәгәрмәчләрен алыштыру, койма буяу, гөлләр күчерү кебек эшләрне бергәләп эшләргә була.

***Фотоальбомнар карау.*** Кайвакыт альбомдагы иске фотоларны карау, кызыклы вакыйгаларны искә алу да күңелгә рәхәт була.

***Өстәл уеннары уйнау.*** Өлкәннәр өчен өстәл уеннары-логика һәм стратегия үсешенә бер адым булса, кечкенәләр өчен вак моториканы, зиһенне үстерүгә бик файдалы булыр.


***Кул эшләнмәләре эшләү.*** Аның өчен интернетта бик гади һәм аңлаешлы инструкцияле видеолар бар.

***Саф һавада йөрү*** Мондый вакыт уздыру онытылмаслык хис-кичерешләр, күңел күтәренкелеге, көч һәм оптимизм гарантияли.





## Язгы табышмаклар

- ✓ Ут та түгел, ук та түгел,
  Күзгә төшә, карны кисә.
  *(Кояш нуры)*
- ✓ Ак юрганымны алып куйдым,
  Яшел юрганымны җәеп кудым.
  *(Яз килү)*
- ✓ Үзе туңа, өйгә керми,
  Үзе жылый да жылый.
  *(Боз сөңгесе)*
- ✓ Агач башында йорты,
  Эчендә яши жырчы.
  *(Сыерчык)*
- ✓ Кара төлке кар астыннан чаба.
  *(Боз астындагы су)*
- ✓ Борынсыз чыпчык боз тишә.
  *(Тамчы)*







## Халык сынамышлары

- ❖ Яз көне эретмичә озак туңдырып торса, жәй коры була.
- ❖ Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.
- ❖ Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.
- ❖ Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.
- ❖ Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.
- ❖ Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.
- ❖ Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.
- ❖ Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.
- ❖ Язын сыерчык иртә килсә, көннәр жылы булыр.
- ❖ Яз көне елгаларда су артмаса,ашлык уңмас.
- ❖ Яз көне хайван аяк эзләре эресә, жылытыр.

**Сәхифәне әзерләделәр:** башлангыч сыйныф укытучылары Абдуллина А.Р., Мөхәмәдиева Н.З.

**Редакция һәм нәшриятның адресы:** 422024, Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 11нче йорт
**E- mail:** Sskor.Ars@tatar.ru

**Социаль челтәр бите:** https://vk.com/77arsk_srkorsa